ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ "
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

СОВЕТ СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦУЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район,**
**село Старые Киязлы, ул. Центральная д.57**
**Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 1061665002332,**
**ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001**

---

КАРАР

№ 35 15 август 2022 нче ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль
районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының
2018 елның 10 маендагы 52 номерлы «Татарстан
Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә
ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы
нигезләмәне раслау хакындагы" карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 маендагы 52 номерлы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турындагы" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 10.8 пункт өстәргә:

Җирлекнең генераль планы проекты һәм җирлекнең генераль планына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар буенча ачык тыңлаулар авыл җирлегенең һәр торак пунктында уздырыла, моңа җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләү очраклары керми, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, ачык тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.

1.2. 7 маддәнең 7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыруны билгеләгән органга, ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр аларны гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертү өчен, тикшерелә торган сорауларга кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен тапшырырга хокуклы:

1) ачык тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән рәвештә;

2) ачык тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә;

3) ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу юлы белән.

1.3 7.3 пунктыннан «Халык тыңлаулары җирлек территориясендә уздырыла» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы рәисе Г.Г.Дәүләтшин